ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында” 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 3 өлешендәге 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле “в” пунктчасы өстәргә:

“в) Россия Федерациясенең ике һәм аннан артык субъекты территориаль планлаштыру схемасын, әлеге схема проектын Татарстан Республикасы территориясенә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешләренә карата әзерләгән очракта (алга таба – Россия Федерациясенең ике һәм аннан артык субъекты территориаль планлаштыру схемасы), Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын;”;

2) 7 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктының “в” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“в) Россия Федерациясенең ике һәм аннан артык субъекты территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы.”;

3) 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“15 статья. **Россия Федерациясенең ике һәм аннан артык субъекты территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы**

Россия Федерациясенең ике һәм аннан артык субъекты территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы Россия Федерациясенең бу субъектларының, шул исәптән Татарстан

Республикасының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү максатларында әзерләнә һәм, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемаларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Россия Федерациясенең әлеге субъектларының, шул исәптән Татарстан Республикасының, социаль-икътисадый үсеш стратегияләре, макрорегионнарның социаль-икътисадый үсеш стратегияләре нигезләмәләренә һәм Россия Федерациясен стратегик планлаштыруның тармак документлары нигезләмәләренә таяна.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ 68-ТРЗ